Республика Татарстан
Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

16.10.2024

№ 7

2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә

**КАРАР ИТӘМ:**

1. Түбән Чыршылы авылының Горький урамындагы 9-нчы номерлы йорт янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 15 ноябренә 11.00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Түбән Чыршылы торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү); (Түбән Чыршылы торак пунктында җирлек Юлы эчендә ремонтлау (ташу, вак таш салу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): трактор тоту (Беларус

МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык- майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу); Түбән Чыршылы торак пунктында);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов